**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.08.2019 № 588

**Авыл җирендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую өчен торак урынының гомуми мәйданының исәп нормасы турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50 нче маддәсе, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль Законының 16 маддәсендәге 1 өлешенең 6 пункты, “Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең федераль стандартлары турында”гы 2005 елның 29 августындагы 541 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Торак урынын яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә кую максатларында гражданнарның гомуми торак мәйданы белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен 18 кв.м. күләмендә билгеләргә.

2. Социаль наем шартнамәсе буенча һәм дәүләт торак программалары буенча гаиләнең бер әгъзасына 18 кв.м күләмендә торак мәйданын бирү нормасын билгеләргә, ләкин ул ялгыз яшәүче граждан өчен 33 кв. м. ким булмаска, ә ике кешедән торган гаилә өчен 42 кв. м. ким булмаска тиеш.

3. Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының “Авыл җирендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую өчен торак урынының гомуми мәйданының исәп нормасы турында”гы 2015 елның 28 апрелендәге 192 номерлы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайттында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Г. Фатыйхова йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Б. Семенычев**